ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» 562-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» 562-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 6 июне
№ 2498-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.Г. Хәбибуллин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясының 1 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 5, № 11 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 1 – 2; 2016, № 1 – 2, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 73 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле «и$^{1}$» пунктчасы өстәп, үзгәреш кертергә:

«и$^{1}$) ул чит ил агенты статусын алганда;».

**2 статья**

Әлеге закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) законнарны «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясе аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 15 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 99-ФЗ номерлы Федераль закон) аерым нигезләмәләренә туры китерүгә юнәлдерелгән.

99-ФЗ номерлы Федераль закон белән федераль законнарда беркетелгән Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару органнары депутатлары вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату нигезләре исемлекләренә, бигрәк тә алар чит ил агенты статусын алган очракта, өстәмәләр кертелә.

Закон проектында «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына төгәлләштерелә торган үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнары актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.